| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2024 елның 8 ноябре № 40/4

Авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына билгеләнгән, гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен түләүсез тапшыруның уртача район нормасы турында

«Татарстан Республикасы Җир кодексының 34 һәм 40 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 29 сентябрендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына билгеләнгән, гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен түләүсез тапшыруның уртача район нормасын, федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очраклардан тыш, 2,3 гектар күләмендә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының «Авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына билгеләнгән, гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен түләүсез тапшыруның уртача район нормасы турында» 2021 елның 27 маендагы 9/7 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы урынбасары, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе урынбасары А.Е. Ярухин